Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 21 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы 45-ТРЗ Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна торак пунктында үткән үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Халык җыены карар итте:

1. «90 % ташлама каралган I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән, балигъ бала тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән тыш, Сосна авыл җирлегенең Түбән Сосна авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр гражданга 2021 нче елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Түбән Сосна авылында урам- юл челтәрен норма таләпләренә туры китерү; зиратларга коймалар сатып алып урнаштыру; 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан сугышчыларга куелган һәйкәл территориясен төзекләндерү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сосна авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга , Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarctan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Ф.С.Габдрахманов